ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙ-
ОНЫ КИРОВ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423747, Киров авылы,
Киров урамы 52 йорт.
тел.факс.: (85552) 3-44-47
e-mail: kirov.sp@yandex.ru

СОВЕТ КИРОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТА-
НЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423747, пос. совхоз им. Кирова,
ул. Кирова, дом 52.
тел.факс.: (85552) 3-44-47
e-mail: kirov.sp@yandex.ru

**РЕШЕНИЕ** — **КАРАР**

18 декабрь 2024 ел — № 25

**"Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге Советының муниципаль вазыйфаларын биләүче затларга һәм Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге Башкарма комитетының муниципаль хезмәткәрләренә премияләр бирү һәм башка өстәмә түләүләр турында Нигезләмә хакындагы" Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге Советының 07.06.2023 ел, № 7 карарына үзгәрешләр кертү турында**

Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге Советының муниципаль вазыйфаларын биләүче затларга һәм Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге Башкарма комитетының муниципаль хезмәткәрләренә социаль гарантияләрне тәэмин итү, хезмәт өчен түләүне тәртипкә китерү һәм камилләштерү, аларның һөнәри хезмәт эшчәнлеген стимуллаштыру максатларында, Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге Советы карар итте:

1. "Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге Советының муниципаль вазыйфаларын биләүче затларга һәм Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге Башкарма комитетының муниципаль хезмәткәрләренә премияләр бирү һәм башка өстәмә түләүләр турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 бүлекнең 1.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«1.1.Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең эшчәнлек нәтиҗәлелеген, җирле үзидарә органнарына йөкләнгән вәкаләтләрне үтәү өчен аларның җаваплылык дәрәҗәсен арттыру, башкарыла торган бурычларның сыйфатын күтәрү, вазыйфаи инструкциядә каралган вазыйфаи бурычларны вакытында һәм намуслы үтәү максатларында муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга, муниципаль хезмәткәрләргә премияләр түләнә:

- ярты еллык өчен эш йомгаклары буенча премия (алда-ярты еллык премия)
- Татарстан Республикасы көненә, җирле үзидарә көненә багышланган.

1.2. «4. Ярты еллык премия» бүлеген өстәргә кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Актаныш муниципаль районы
Киров авыл җирлеге Совет рәисе — И.Х.Магданов

Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге Советының «18»12. 2024 № 25 карарына 1 нче кушымта

«4. Ярты еллык премия

4.1. Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге Советының муниципаль вазыйфаларын биләүче затларга һәм Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге Башкарма комитетының муниципаль хезмәткәрләренә, муниципаль хезмәткәрләр өчен акчалата түләү һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар өчен бүләкләү күләмендә ярты еллык премияләр түләнә.

2.2. Муниципаль хезмәткәрләргә, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга ярты еллык премияләр кими:

- билгеләнгән күләмнең 10% на - җирлек башлыгы, җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан гамәлдәге законнар нигезендә үз вәкаләтләре кысаларында бирелгән йөкләмәләрне вакытында һәм сыйфатсыз үтәгән өчен;

- билгеләнгән күләмнең 15% на - муниципаль программаларны үтәүчеләргә һәм региональ һәм федераль программаларны гамәлгә ашыру өчен җаваплыларга программаны яисә аның аерым чараларын вакытында һәм сыйфатсыз гамәлгә ашырган өчен, алар район бюджетының программаны гамәлгә ашыруга юнәлтелгән акчаларын нәтиҗәле һәм максатчан файдалануны тәэмин итмәгән өчен;

- билгеләнгән күләмнең 25% на - җирлек башлыгы, җирлек башкарма комитеты җитәкчесенең гамәлдәге закон нигезендә үз вәкаләтләре кысаларында бирелгән ашыгыч һәм аеруча мөһим беркетмә йөкләмәләрен сыйфатсыз үтәгән өчен;

- билгеләнгән күләмнең 10% на -гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау сроклары үтәлмәгәндә, шул исәптән башка учреждениеләрдән, оешмалардан килгән мөрәҗәгатьләр буенча, хезмәт документлары белән эшләү тәртибе бозылганда;

- билгеләнгән күләмнең 15% на - бер дисциплинар җәза булганда;

- билгеләнгән күләмнең 25% на - ике дисциплинар җәза булганда;

- билгеләнгән күләмнең 20% на - хезмәтне саклау һәм техника куркынычсызлыгы, янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәмәгән өчен;

- билгеләнгән күләмнең 20% на - хезмәт дисциплинасын бозган өчен, эш вакыты режимы өлешендә, бер ай эчендә, нигезле сәбәпләрсез, һәркайсы 10 минуттан артык дәвам иткән эшкә икедән артык соңга калу теркәлгән очракта.

2.3. Ярты еллык премияләр түләнми:

- 3 һәм аннан күбрәк документны (мөрәҗәгатьләрне, хатларны)карау сроклары бозылган очракта;

- квартал дәвамында җирлек башлыгы, җирле үзидарә органы җитәкчесенең 3 һәм аннан күбрәк беркетмә йөкләмәләрен үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү;

- муниципаль мөлкәткә милекне юкка чыгармаган матди зыян китерү;

- вазыйфаи бурычларын үтәгәндә билгеле булган хезмәт мәгълүматын ачу;

- муниципаль хезмәт узуга бәйле чикләүләрне һәм тыюларны, хезмәттә үз-үзеңне тоту бурычларын һәм кагыйдәләрен, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәү, коррупциягә каршы көрәш максатларында билгеләнгән бурычларны үтәмәү.

2.4. Ярты еллык премия күләме «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, рәисләрнең, рәис урынбасарларының, аудиторларның хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары нигезендә билгеләнә торган муниципаль хезмәткәрләр өчен акчалата түләү һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар өчен бүләкләү күләме белән чикләнә.

2.5. Эш бирүче дисциплинар түләтү кулланылган көннән алып бер ел узганчыга кадәр аны хезмәткәрдән үз инициативасы, хезмәткәрнең үз үтенече, аның турыдан-туры җитәкчесе яисә хезмәткәрләрнең вәкиллекле органы үтенече буенча алырга хокуклы.

2.6. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга, эшкә сәләтсезлек кәгазе буенча больничныйда булган, хезмәткәрләр саны яисә штаты кыскартылуга бәйле рәвештә сәламәтлеге торышы буенча медицина бәяләмәсе нигезендә эштән азат ителгән, башка эшкә күчерелүгә, уку йортына керүгә, пенсиягә чыгуга, хәрби хезмәткә чакырылуга бәйле муниципаль хезмәткәрләргә ярты еллык премия эшләп чыгарылган вакытка пропорциональ рәвештә түләнә.

2.7. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга, муниципаль хезмәткәрләргә әлеге Нигезләмәнең 2.6 п.каралмаган башка нигезләр буенча эштән азат ителгән, шулай ук «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 1 пунктының 2, 3 өлешләрендә, 71 статьясында, 77 статьясындагы 7-9 пунктларында каралган нигезләр буенча муниципаль хезмәттән азат ителүгә бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 81 статьясында (1, 2, 4 пунктларыннан тыш), 83 статьясының 4, 8, 10, 11 пунктларында, 84 статьясында ярты еллык премияләр түләнми.

2.8. Түләү вакытына муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга, муниципаль хезмәткәрләргә ярты еллык премия түләнми:

- Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән яшькә җиткәнче баланы карау ялында, йөкләлек һәм бала табу ялында булганнарга;

- премияләр бирелә торган чор дәвамында акчалата түләүләрен саклап калмыйча ялда булганнарга.

- хезмәткәр эшкә алынган ярты еллык сынау срогында.

2.9. Әлеге Нигезләмәдә каралган ярты еллык премияләр пенсияләр, отпусклар, вакытлыча эшкә яраксызлык буенча пособиеләр һ. б. исәпләү өчен уртача хезмәт хакы составында исәпкә алына»